Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлеге Иске Үргәагар авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 23 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 17 номерлы Әлки муниципаль районының «Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 16 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» турындагы карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегенең Иске Үргәагар авылында 2019 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге составына керүче Иске Үргәагар авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә килешәсезме:

- урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алуга, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә һәм урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләүгә -90 сум.;

-су үткәргечләрне реконструкцияләү, су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау буенча проект-смета эшләре төзүгә, проект-смета эшләрен башкаруга һәм Яңа Үргәагар авыл җирлегенең торак пунктларында су анализы алу өчен түләүгә бәйле чыгымнарга - 100 сум;

- җирлек эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга (туфрак, ком, вак таш сибү, тигезләү, юлларга сибү өчен төзелеш материаллары сатып алу, чаптыру) - 255 сум;

- һәйкәл төзелешенә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу (белгеч эше өчен түләү) - 85 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан

сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм  һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алуга, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә һәм урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләүгә -90 сум.;

-су үткәргечләрне реконструкцияләү, су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау буенча проект-смета эшләре төзүгә, проект-смета эшләрен башкаруга һәм Яңа Үргәагар авыл җирлегенең торак пунктларында су анализы алу өчен түләүгә бәйле чыгымнарга - 100 сум;

- җирлек эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга (туфрак, ком, вак таш сибү, тигезләү, юлларга сибү өчен төзелеш материаллары сатып алу, чаптыру) - 255 сум;

- һәйкәл төзелешенә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу (белгеч эше өчен түләү) - 85 сум.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Үргәагар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлеге башлыгы: Ә. Ә. Рәхимҗанов